КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 30 май

г.Казань

№ 660

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2007 ел, 5 февраль, 32 нче карары белән расланган Эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2007 ел, 5 февраль, 32 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 30 декабрь, 1141 нче; 2020 ел, 13 июль, 584 нче; 2021 ел, 31 май, 408 нче; 2022 ел, 11 февраль, 114 нче; 2022 ел, 10 июнь, 546 нчы; 2022 ел, 16 декабрь, 1354 нче, 2023 ел, 2 май, 549 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.3 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3 Сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айның 1нче көненнән дә иртәрәк булмаган датага сайлап алуда катнашуны планлаштырган эш бирүчеләр түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:»;

2.4 пунктның уналтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гаризалар әлеге Тәртипнең 2.1 пункты нигезендә сайлап алуны уздыру турында игълан итүдә билгеләнгән вакыт дәвамында кабул ителә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин